ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге составына керүче Урта Кирмән торак пунктында 2021 елга үзарасалым кертү турында

№ 3 13 ноябрь 2020 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчыстатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлегененҮрта Кирмән торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Урта Кирмән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, БөекВатансугышы һәм хәрбихәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, БөекВатансугышында һәм хәрбихәрәкәтләрдәкатнашканнарның тол хатыннары, күпбалалыгаиләләр, көндезгебүлектәбелемалучыстудентлар, Россия Армиясесафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 400(дүртйөз) сумм күләмендә үзарасалым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:
- Урта Кирмән авылында су алу колонкаларын төзекләндерү(павильон сатып алу һәм урнаштыру);
- Урта Кирмән авылы Муса Җәлил урамы буенча юлга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
-Урта Кирмән авылы урам утлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру(килешү буенча эш өчен түләү);
- Урта Кирмән авылында юлларны кардан чистарту.

3.Әлеге карарны Урта Кирмән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнарҗыенындарәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Б.Ф.Хәсәнов